КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 24 июль г.Казань № 591

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эш бирүчегә иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәтүче учреждениеләрдән азат ителгән һәм эшкә (шул исәптән резервлана торган эш урыннарына) урнаштырылган затларга хезмәт өчен түләү чыгымнарының бер өлешен компенсацияләү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 28 февраль, 131 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эш бирүчегә иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәтүче учреждениеләрдән азат ителгән һәм эшкә (шул исәптән резервлана торган эш урыннарына) урнаштырылган затларга хезмәт өчен түләү чыгымнарының бер өлешен компенсацияләү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 28 февраль, 131 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ирекtән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәтүче учреждениеләрдән азат ителгән һәм эшкә (шул исәптән резервлана торган эш урыннарына) урнаштырылган затларга хезмәт өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен эш бирүчегә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында»;

1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу карарга теркәлгән Ирекtән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәтүче учреждениеләрдән азат ителгән һәм эшкә (резервлана торган эш урыннарына) урнаштырылган затларга хезмәт өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен

эш бирүчегә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен расларга.»;

әлеге карар белән расланган Эш бирүчегә иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәтүче учреждениеләрдән азат ителгән һәм эшкә (резервлана торган эш урыннарына) урнаштырылган затларга хезмәт өчен түләү чыгымнарының бер өлешен компенсацияләү тәртибен бу карарга теркәлгән кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2014 ел, 28 февраль, 131 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 24 июль, 591 нче
карары редакциясендә)

Иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәтүче учреждениеләрдән
азат ителгән һәм эшкә (резервлана торган эш урыннарына) урнаштырылган
затларга хезмәт өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен эш бирүчегә
Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү
ТӘРТИБЕ

1. Бу Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 9 август, 553 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү» дәүләт программасын тормышка ашыру максатларында эшләнде һәм иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәтүче учреждениеләрдән азат ителгән һәм эшкә (резервлана торган эш урыннарына) урнаштырылган затларга хезмәт өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен теләсә кайсы хокук һәм милек рәвешләрендәге оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия (алга таба – субсидия) бирү механизмын билгели.

2. Субсидия эш бирүчеләргә иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәтүче учреждениеләрдән азат ителгән эшкә (резервлана торган эш урыннарына) урнаштырылган затларга хезмәт өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау максатларында бирелә.

3. Субсидияләр тиешле финанс елына субсидияләр бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары бюджет акчасын алучылар буларак билгеләнгән тәртиптә ирештерелгән Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләренә (алга таба – халыкны эш белән тәэмин итү үзәге) бирелә.

4. Бу Тәртипне тормышка ашыру өчен түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән зат – азат ителгән көннән өч ел дәвамында иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәтүче учреждениеләрдән азат ителгән зат;

резервлана торган эш урыны – иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәтүче учреждениеләрдән азат ителгән затларны эшкә урнаштыру өчен эш бирүчеләргә билгеләнгән эш урыннарының билгеле бер саны.

5. Субсидияләр үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыра торган һәм билгеләнгән тәртиптә теркәлгән эш бирүчеләргә бирелә.

Субсидия бирү турында шартнамә (алга таба – шартнамә) төзү планлаштырыла торган ай алдыннан килүче айның бересенә түбәндәге эш бирүчеләр субсидия алучы була алмый:

Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пеняләр, штрафлар, процентлар түләү буенча башкарылмаган йөкләмәләре булган;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокук актлары нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында вакытында түләнмәгән башка бурычлары булган;

үзгәртеп оештыру, ябу, банкротлык процессында булган, индивидуаль эшмәкәр буларак эшчәнлеген туктаткан;

чит ил юридик затлары, шулай ук Россия юридик затлары (аларның устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясенең Финанс министрлыгы белән раслана торган Салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм финанс операцияләрен үткәргәндә мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмый торган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория аның теркәлү урыны булган чит ил юридик затларның катнашу өлеше барысы бергә 50 проценттан артыграк булган) булган;

башка норматив хокук актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен акча алучы булган.

6. Субсидия бирү чоры дәвамында эш бирүче тарафыннан эш бирүче гаризасында күрсәтелгән эш урыннары саклану субсидия бирү нәтиҗәлелегенең күрсәткече булып тора.

Нәтиҗәлелек күрсәткече түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$R=S_{rm},$$

монда:

R – нәтиҗәлелек күрсәткече;

$S_{rm}$ – субсидия бирү чоры дәвамында сакланган эш урыннары.

7. Субсидия күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S = Ч \times N \times P,$$

монда:

S – субсидия күләме, сум;

Ч – гариза нигезендә эш бирүче эшкә урнаштырырга планлаштыра торган гражданнар саны;

N – эшкә урнаштырылган бер гражданның 1 айга хезмәт өчен түләү чыгымнарын каплауның Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән минималь хезмәт өчен түләү күләменә тигез булган, бюджеттан тыш дәүләт фондларына иминият кертемнәре суммасына арттырылган күләме;

P – эшкә урнаштырылган гражданга хезмәт өчен түләү чыгымнарын каплау

айлары саны.

Эш бирүченең гражданнар хезмәте өчен түләү чыгымнарын каплау шартнамә төзегәннән соң һәм агымдагы елның 20 декабренә кадәрге (20 декабрьне кертеп) чорда гамәлгә ашырыла.

8. Субсидия алу өчен эш бирүчеләр, агымдагы елның 1 октябреннән дә соңга калмыйча, эш белән тәэмин итү үзәгенә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча түбәндәгеләрне кертә:

бу Тәртипкә теркәлгән кушымтада бирелгән форма буенча гариза;

юридик затны дәүләт теркәвен алу турында таныклык күчермәсе яисә индивидуаль эшмәкәр буларак физик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе яисә Юридик затларның (Индивидуаль эшмәкәрләрнең) бердәм дәүләт реестрына язу бите күчермәсе);

салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсе;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан, Индивидуаль эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан гариза бирү көненә кадәр кимендә өч айдан да иртәрәк бирелмәгән эш бирүче турындагы мәгълүматлары булган өземтәнең таныкланган күчермәсе;

салым органының Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пеняләр, штрафлар, процентлар түләү буенча башкарылмаган йөкләмәләре булмау турындагы белешмә кәгазе;

җитәкче һәм баш бухгалтер имзасын куйган, мөһер белән беркетелгән (мөһер булганда) субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокук актлары нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмау турындагы белешмә кәгазе (ирекле рәвештә);

җитәкче һәм баш бухгалтер имзасын куйган, эш бирүченең башка норматив хокук актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен акча алучы булмавын раслый торган белешмә кәгазе;

эш бирүченең җитәкчесе имзасын куйган, эш бирүченең үзгәртеп оештыру, ябу, банкротлык (юридик затлар) процессында булмавын, индивидуаль эшмәкәр буларак эшчәнлеген туктатмавын раслый торган белешмә кәгазе.

9. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге гаризаны халыкны эш белән тәэмин итү үзәге тарафыннан билгеләнгән форма буенча эшләнә торган субсидияләр бирү турындагы гаризаларны теркәү журналында гариза кергән көндә гаризалар керү чиратын саклап терки. Гариза почта аша кергәндә, халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә почта аша гариза керү көне һәм вакыты күрсәтелеп, ул кергән көндә гаризаларны теркәү журналында теркәлә.

Тиешле финанс елына субсидияләр бирү өчен бюджет йөкләмәләре лимитлары суммасы аларны үтәү белән төгәлләнә торган һәм элегрәк теркәлгән гаризалар буенча карарлар кабул ителгәннән соң кергән яки гаризаларны кабул итү вакыты тәмамланганнан соң (шул исәптән почта аша) кергән гаризалар каралмый һәм кире кайтарылмый, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге эш бирүчегә бу турыда

гариза кергән көннән соң өч эш көне эчендә гаризада күрсәтелгән адрес буенча язма хәбәр итә.

10. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге гариза теркәлгән көннән эш көннәрендә исәпләнүче биш көн эчендә гаризаны карап тикшерә һәм субсидия бирү яки аны бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

бу Тәртипнең 8 нче пункты белән күздә тотылган документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

эш бирүче тарафыннан тапшырылган гаризадагы һәм бу Тәртипнең 8 нче пунктында күрсәтелгән документлардагы мәгълүмат дөрес булмау;

гариза бирү көненә агымдагы финанс елы өчен субсидия бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары бетү.

11. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге субсидия бирү турында карар кабул ителгәннән көннән эш көннәрендә исәпләнүче өч көн эчендә кабул ителгән карар турында хәбәрнамә һәм халыкны эш белән тәэмин итү үзәге белән эш бирүче арасында Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә төзелә торган шартнамә проектын ике нөсхәдә җибәрә.

12. Эш бирүче үз гаризасы нигезендә шартнамә проектын алган көннән эш көннәрендә исәпләнүче өч көн эчендә аны рәсмиләштерә, аңа имза куя һәм шартнамәнең ике нөсхәсен халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә җибәрә.

13. Шартнамәдә субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше, субсидияне күчерү тәртибе, нәтиҗәлелек күрсәткече, нәтиҗәлелек күрсәткеченә ирешү турында хисаплылык бирү вакытлары һәм формасы, субсидия алучы тарафыннан кире кайтару очраклары һәм тәртибе, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге, Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан субсидия алучының аны бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвенә тикшерүләр үткәрүне гамәлгә ашыру, субсидия алучының (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, хуҗалык ширкәтләреннән һәм устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында җәмгыятьләрдән, шулай ук устав (җыелма) капиталларында мондый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр катнашында коммерция оешмаларыннан тыш) халыкны эш белән тәэмин итү үзәге, Министрлык һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан субсидия алучының аны бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвенә тикшерүләр үткәрүне гамәлгә ашыругы ризалыгы, субсидия алучы тарафыннан бу Тәртип һәм төзелә торган шартнамә шартларын үтәү турында нигезләмәләр карала.

14. Эш бирүче үзенә субсидия күчерү өчен ай саен, үткән айның өчен эш йомгаклары буенча эш бирүчедә билгеләнгән эш хакын түләү вакыты чыккан көннән биш эш көненнән дә соңга калмыйча, халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә үзе таныклаган түбәндәге документлар күчермәләрен кертә:

граждан белән төзелгән хезмәт шартнамәсе, эшкә алу турында боерык;

эш вакытын исәпкә алу табеле;

исәп-хисап ведомосте (эш хакының исәпләнгән суммасы турында);

бюджеттан тыш дәүләт фондларына иминият кертемнәре буенча исәпләүләрнең ирекле формада төзелгән исәп-хисабы;

түләү ведомосте (эш хакының түләнгән суммасы турында) яки гражданнарның кредит оешмаларындагы шәхси исәпләренә эш хакы суммасын күчерү турында түләү йөкләмәсе;

бюджеттан тыш дәүләт фондларына иминият кертемнәрен күчерү турында түләү йөкләмәсе.

15. Субсидия акчасын күчерү халыкны эш белән тәэмин итү үзәге тарафыннан карар кабул ителгәннән соң һәм халыкны эш белән тәэмин итү үзәге хисабына акча кергәннән соң эш көннәрендә исәпләнүче 10 көн эчендә, эш бирүче тарафыннан бу Тәртипнең 14 нче пункты һәм төзелгән шартнамә шартлары үтәлгәндә, эш бирүченең һәр үткән айда башкарылган эш хакын түләүгә чыгымнарын ай саен каплау юлы белән этаплап гамәлгә ашырыла.

16. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге акчаны эш бирүчеләрнең Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап исәпләренә күчерә.

17. Бирелгән субсидияләр халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең түбәндәге тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнүче 30 көн эчендә субсидияләр алучылар тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш:

халыкны эш белән тәэмин итү үзәге, Министрлык һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган, алар бирелгән вакытта билгеләнгән шартлар субсидия алучы тарафыннан бозылу очраклары булганда, тулы күләмдә;

нәтиҗәлелек күрсәткеченә ирешмәгән очракта, шартнамәдә каралган нәтиҗәлелек күрсәткеченең ирешелмәгән мәгънәсе өчен субсидия суммасыннан бер процент күләмендә.

18. Эш бирүче тарафыннан әлеге пункт белән билгеләнгән акчаны ирекле рәвештә кире кайтару вакыты бозылганда, бу Тәртипнең 17 нче пункты белән күздә тотылган очракларда, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге әлеге вакыт чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнүче җиде көн эчендә әлеге акчаны закон белән билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри түләттерү буенча чаралар күрә. Шул ук вакытта субсидия алучы, акчаны кире кайтарудан тыш, субсидия алганнан соң киләсе көннән башлап аны кире кайтару көненә (кире кайтару көнен кертеп) кадәр һәр түләмәгән көн өчен бурыч суммасыннан 0,03 процент күләмендә пеня түли.

19. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге, Министрлык һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы субсидия алучыларның субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра.

20. Эш бирүчеләргә бирелгән субсидия акчасыннан максатчан файдалануны тикшерүдә тотуны Министрлык һәм халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре гамәлгә ашыра.

21. Эш бирүчеләр халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә бирелгән мәгълүматларның дөреслеге өчен закон нигезендә җавап бирә.

---

Иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәтүче учреж-дениеләрдән азат ителгән һәм эшкә (резервлана торган эш урыннарына) урнаштырылган затларга хезмәт өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен эш бирүчегә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә
кушымта

Форма

______________________________________
(халыкны эш белән тәэмин итү үзәге исеме)
______________________________________

___________________________ директоры
______________________________________
(директорның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)

20 ___ елга
иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәтүче учреждениеләрдән
азат ителгән һәм эшкә (резервлана торган эш урыннарына) урнаштырылган
затларга хезмәт өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен эш бирүчегә
Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирүгә
гариза

______________________________________________________________________
(эш бирүченең исеме, адресы)
иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәтүче учреждениеләрдән азат ителгән _______ затны эшкә урнаштырырга әзер.

Тәкъдим ителә торган эш урыннары буенча хезмәт шартлары һәм аның төп тасвирнамәләре:

| Т/с | Күрсәткечләр | Эш урыннары турында мәгълүматлар | Искәрмәләр |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Эш төрләре һәм характеры | | |
| 2. | Эш урыннары саны | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3. | Эшкә урнаштырыла торган граждannar саны (человек) | | |
| 4. | Һөнәр (белгечлек) | | |
| 5. | Белем (һөнәри-квалификация таләпләре) | | |
| 6. | Эш атнасының озынлыгы (көннәрдә) | | |
| 7. | Эш режимы (1, 2, 3 смена) | | |
| 8. | Эшнең башлану һәм тәмамлану вакыты (сәгать) | | |
| 9. | Хезмәт өчен түләү дәрәҗәсе [1]: (сум) | | |
| 9.1. | Эш хакының даими өлеше (хезмәт хакы, тариф ставкасы) | | |
| 9.2. | Эш хакының алмашынучан өлеше (стимуллаштыру характерындагы өстәмәләр һәм өстәмә түләүләр, премияләр һәм башка кызыксындыра торган түләүләр) | | |
| 10. | Эш урыны урнашу (адресы) | | |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәтүче учреждениеләрдән азат ителгән һәм эшкә (шул исәптән резервлана торган эш урыннарына) урнаштырылган затларга хезмәт өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен эш бирүчегә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 28 февраль, 131 нче карары белән расланган Иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәтүче учреждениеләрдән азат ителгән һәм эшкә (шул исәптән резервлана торган эш урыннарына) урнаштырылган затларга хезмәт өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен эш бирүчегә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе нигезендә иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәтүче учреждениеләрдән азат ителгән һәм эшкә (шул исәптән резервлана торган эш урыннарына) урнаштырылган затларга хезмәт өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидия бирү турында шартнамә төзүне сорыйбыз.

Иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәтүче учреждениеләрдән азат ителгән һәм эшкә (шул исәптән резервлана торган эш урыннарына) урнаштырылган затларга хезмәт өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен ______________________

(суммасы саннар белән языла)

(________________________________________________________________) сум

(суммасы тутырып языла)

күләмендә акча таләп ителәчәк.

Түләү реквизитлары ______________________________________________:

(эш бирүченең тулы исеме)

_____________________________________________________________________

(Россия Банкы учреждениесе, кредит оешмасы исеме, БИК, исәп-хисап исәбе)

[1]Бу пунктта хезмәт өчен түләү системасы нигезендә эш хакының төп өлешләре турында мәгълүматлар күрсәтелә.

Бу гаризага түбәндәгеләр теркәлә:

1. ______________________________________________________________
2. ______________________________________________________________

Җитәкче ______________________ ____________________________________

(имза) (имза тулысынча)

М.У.[2]

---

[2]Мөһер булганда.